Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**21.10.2022** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы 45-ФЗ Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында үткән үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча **Х**алык җыены карар итте:

1. 90% ташлама каралган I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән, балигъ бала тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан тыш, Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр гражданга 2023 нче елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
   - Түбән Сосна авылында урам- юл челтәрен норма таләпләренә туры китерү,
   - Түбән Сосна авылында агач кисү,
   - Түбән Сосна авылында инеш территорияләрен төзекләндерү.
3. Халык җыены нәтиҗәләрен Сосна авыл җирлегенең мәглүмати стендларында урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов